ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.12.2023 ел Баулы шәһәре №225

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 24 августындагы 172 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасының 2010 елның 30 июлендәге 60-ЗРТ номерлы Законын үтәү нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 26 гыйнварындагы 10 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«Статья 2.1.» юлының беренче баганасын «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма үз атамасы турында мәгълүматны һәм билгедә урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуларга карата) сүзләре белән тулыландырырга;

3.6.юлының беренче баганасында «шәһәр округлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Статья 3.10.» юлының беренче баганасын «(гражданнарга карата)» сүзләре белән тулыландырырга;

«Статья 5.6» юлының беренче баганасын «(тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә башкарыла торган муниципаль ташуларга карата)» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров